УЙЛАНЫЙК МИЛЛӘТТӘШЛӘР

# Телсез калса, татар кем булыр

*Һәр халыкнын теле бер генә ич.*
*Телсез калса, татар кем булыр.*
*Бу хурлыкка түзми, көнә-көндез.*
*Зәңгәр күктән йолдыз егылыр.*

**Нур ӘХМӘДИЕВ.**



Зәңгәр күктән хурланып йолдыз егылмасын өчен татарым без нишләргә тиеш?

Бу уй үзен хөрмәт иткән, үз халкын санлаган һәр татар кешесен борчысын иде.

Без Әсәкәй татар активистлары район милли мәдәният мөхтәрияте белән берлектә халкыбыз алдында торган бу четерекле мәсәләне хәлебездән килгәнчә чишәргә тырышабыз.

Февраль аенда зурдан кубып быел Бөтендөнья татар конгрессы тәкъдиме буенча “Ак хисләр” фестиваль-конкурсын өлкәкүләм итеп үткәрдек. Әсәкәй район кешеләре килгән кунаклар барысы да бик кәнәгать булдылар бу мәдәни-чарадан.

Фестивальнең алдагы көнендә, балалар, яшьләр һәм гөмүмән төрле яшьтәге халык алдында татарыбызның мәртәбәле шәхесләре Мәскәүдән Нәзифә Кәримова (Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, бәллүр каләм иясе, язучы, “Азатлык” радиосы журналисты), Роза Хабибуллина (Татарстанның атказанган артисты), Казаннан Миңгол Галиев (Татарстанның халык артисты, доцент музыка факультетында), Гөлназ Шәйхи (Бөтендөнья Татар Конгрессының вәкиле, журналист) чыгыш ясадылар. Нәзифә Кәримованың “Сагынасыңмы дип сорыйлар…” дигән китабы буенча фикер алышу булды. Аның хикәяләре буенча район мәдәният йорты сәхнәләштерген театраль чыгышлар күрсәтте.

Балаларыбыз, яшьләребез үзенең туган телен яхшы белгән, мәктәптә татар телен тулысынча үзләштерген зур шәхесләрне күрделәр. Аларга татар теле тормышта үз юлларын табарга комачауламаган. Киресенчә ана сөте белән бирелгән газиз тел чын кешеләр булып үсеп тормыш итәргә ярдәм иткән һәм итә дә.



Октябрь азагында менә инде икенче ел без район мәдәният йорты, район милли-мәдәният мөхтәрияте “Алтын- көз” исемле балалар һәм яшь-үсмерләр өчен фестиваль-конкурс үткәрәбез. Быел Ильдус Давлятов тәкъдиме буенча бу чарага күрше район балаларын да чакырдык. Абдулино, Пономаревка, Матвеевка, Бугурусланнаң күп кенә талантлы балалар үзләренең сәләтләрен күрсәттеләр.

Өч сәгать буена “Алтын-көз” сәхнәсеннән татар телендә җырлар, шигырьләр яңгырады. Татар халык биюләре җырга караганда әзрәк булсалар да лаеклы урын биләделәр сәхнә түрендә. Ә Дусмәт авылы “Яшьлек” бию ансамбле кызлары фестивальның иң зур бүләген Гран-При-ны яулап Пономаревка районына телевизор алып кайтып киттеләр.Бу бәйрәмгә килеп чыгыш ясаган балалар берсе дә бүләксез калмады. Бүләкләр алуда саллы ярдәм иттеләр безнең районның уңган-булган егетләре — генерль спонсор Ильдус Давлятов, аннан кала Рөстәм Гилязов (юллар төзү идарәсе җитәкчесе), Ришат Галимов (фермер хуҗалыгы җитәкчесе). Шулаюк кулларыннан килгәнчә ярдәм иттеләр Хәйдәр Хабиров, Әхмәт Шагвалеев, Салават Валеев, Фәрит Нугуманов.

“Алтын-көз” фестивале артистлары иң кечесе 5 яшь иң зуры 15 яшьлек барсы да татар телендә чыгыш ясадылар. Ә Әсәкәй халкы яше-карты галаконцертны хозурланып карап утырдылар.

Балаларыбызның җырларында чишмәләр чыңы чагылды, әнкәйләрнең йөрәк сагышы, туган якларының гүзәллеге.

Сәхнәдә татар халкының бөек шагыйрьләре Габдулла Тукай, Резеда Вәлиева, Равиль Файзуллин әсәрләре нәфис сүз номинациясендә яңгырадылар.

Ә “Алтын көзебезнең” мәртәбәле кунагы Резеда Вәлиеваның шигырьләре һәм “Ипекәемипекәй” сценарие аеруча җылы кабул ителдәләр тамашачы тарафыннаң. “Ипекәем-ипекәй” театраль күренешне иң кечкенә артистлар Яңа Солтангол авылыннаң “Чишмәкәй” балалар бакчасы күрсәтте.

Шагыйрә Резеда Вәлиеваның “Әбине җәлләп кенә” шигырен сөйләп Эльвир Фаттахов беренче дәрәҗә диплом алды.Тамашачы Яң Солтангол авылыннаң 11 яшьлек нәфис сүз остасын көчле алкышлар белән озатты.

Бу авылның балалары нәфис сүз осталыгында башкалардан аерылып тордылар.Балалар бакчасы һәниләреннән алып өлкән сыйныфта укучыларына кадәр. Мәсәлән Эльза Бакирова Габдулла Тукайнын “Су анасын” сөйләп шулаюк 1 дәрәҗә диплом һәм тузан суырткыч белән бүләкләнде.

Бу уңышлар әлбәттә Яңа Солтанголда туган телгә булган өметле карашны чагылдыра.

Г. Тукайның “Су анасын” татар теле укытучысы Энҗе Лутфуллина әзерләде, ә “Әбине җәлләп кенә” шигырын мәдәният йорты директоры Халидә Давлетзянова.

“Алтын көз” фестиваль-конкурсын әзерләгәндә балаларның туган телебезгә, татар мәдәниятенә булган җылы карашлары куандырды. Моны ата-аналар да хупласыннар иде. Чөнки Әсәкәй авылында кайбер гаиләләрдә татар теленә караш битараф хәлдә. Бу бик аяныч. Тормыш тәҗрибәсе буенча күп татар кешеләре туган телләренең кирәклеген урта буын яшенә җиту белән аңлыйлар һәм бик үкенәләр татар телендә сөйләшә һәм укый алмауларына. Ә аларны бу тиңсез хәзинәдән мәхрүм итүче иң беренче чиратта әниләре һәм әтиләре бит.

Мисал өчен чит илләрдә яшәүче безнең кан-кәрдәшләр үзләренең татарлыкларын гасырлар буенча саклап балаларына ана телен өйрәтеп яшиләр.

Ә нигә без Рәсәй татарлары үзебезнең гәзиз туган телебездән балаларыбызны аерырга тиеш? Алдагы тормышларында үсеп җиткәч алар безне кичерерме соң моның өчен? Уйланыйк милләттәшләр.

Балаларыбыз моңлы җырларыбызны тыңлап бөек шагыйрьләребезнең, язучыларыбызның әсәрләрен укып аңлы гыйлемле кешеләр булып үсеннәр.

Суземне йомгаклау алдыннаң киләчәк “Алтын-көз- 2009” фестиваленә телэкләремне җиткерәсем килә. Сәхнәдә эстрада җырлары белән бер рәттә күбрәк татар халык җырлары яңгырасын иде. Ул җырларда халкыбызның җәүһәргә тиң күңел мирасы тупланган бит.

Бу киңәш беренче чиратта мәдәният хезмәткәрләренә һәм укытучыларга юллана.

Шулаюк нәфис сүз осталары һәм татар биюләредә җырчылардан калышмыйча 2009 елның фестивалендә ярышсыннар иде.

**Зәйтүнә ВАЛИШИНА.**
**Әсәкәй район мәдәният йорты директоры;**
**“Чишмә” халык фольклор ансамбле җитәкчесе;**
**Россияның атказанган мәдәният хезмәткәре.**

**На снимках:** фрагменты выступлений юных артистов.



